Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

20.03.2023 ел Менделеевск ш. №180

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1.Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2017 елның 8 августындагы 106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.4 бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12) аларга чит ил агенты статусы алу.»

1.2. Нигезләмәнең 4.5 бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

«5) аларга чит ил агенты статусы алу.»

1.3. Нигезләмәнең 6.4 бүлегендәге 2, 3 пунктның А пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе;»

1.5. 6.4 бүлегенең 2, 4 пунктының пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) белән» сүзләренә алмаштырырга.

1.6. Нигезләмәнең 2.3 бүлегендәге 3 пунктның 6 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

1.7. Нигезләмәнең 3.8 бүлегенең 3,8,9,10 пунктларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) » сүзләренә алмаштырырга.

1.8. Нигезләмәнең 3.8 бүлегенең 9 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: www.mendsleevsk.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын үтәү буенча даими комитетка йөкләргә.

Совет рәисе Р.И.Беляев